ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

КАРАР

2021 елның «03» февраленнән № 46

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Яңа Чишмә муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» 2013 ел, 25 сентябрь, 406 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

2020 елның 1 мартындагы 35-ФЗ номерлы ана (гаилә) капиталы средстволарын куллануга бәйле мәсьәләләр буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында Федераль законның 4 статьясының 2 пункты. Татарстан Республикасының 2020 елда берләштерелгән бюджетын үтәү йомгаклары һәм Татарстан Республикасы финанс, казначылык һәм салым органнарының 2021 елга бурычлары буенча Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсе, Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсенең уртак коллегиясенең 04.01.2021 № ПР-3 беркетмәсенең 24, 25 пунктларын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының «Яңа Чишмә муниципаль районында мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга социаль ярдәм чаралары күрсәтү турында» 25.09.2013 ел, № 406 карары белән расланган (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 17.01.2014 ел, № 15, 14.02.2017 ел, № 84, 19.01.2017 ел, № 25, 16.09.2019 ел, № 230, 21.04.202020 ел, № 94 карарлары белән

кертелгән үзгәрешләр белән) мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре Тәртибенең 2.1 пунктына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «г)» пунктчасындагы түбәндәге сүзләрне төшереп калдырырга: "Опекага алынган балага компенсация билгеләү өчен өстәмә рәвештә җирле үзидарә органнарының баланы опекага алу турындагы карарыннан өземтә бирелә».

1.2. аңа түбәндәге эчтәлекле «к) " пунктчасы белән өстәргә:

"к) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында белешмә.»

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http:// pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фәсахов